Татарстан Республикасы театрлары

Театр

Халыкка дәрсе гыйбрәттер театр,
Күңелдә йоклаган дәртне уятыр.

Театр — яктылыкка, нурга илтә,
Кире юлга җибәрми, уңга илтә.

Театр көлдерәдер, уйнатадыр,
Тагы үткән гомерне уйлатадыр.

Күрерсең анда үз хәлең, көләрсең
Көләрлек булса, булмаса — еларсың.

Күрерсең тормышың нинди: җитешме?
Җитеш булмаса, кай җире җитешми?

Төзәтерсең шуны, тәкмил итәрсең,—
Шулай шактый белем тәхсил итәрсең.

Үсәр яхшылыгың, син яхшы булсаң;
Җылы канлы итәр ул, вәхши булсаң.

Тигез күрә бөтен җанны театр:
Кирәк кол бул, кирәксә император.

Мөкаддәс ул, бөек ул, гали зат ул;
Тәмам хөр ул, вә бик киң ул, азат ул.

Вә ул дарел-голүм, дарел-әдәптер,
Холыкларны төзәтмәккә сәбәптер.

Вәләкин шарты бар: яхшы төзелсә,
Әгәр һиммәт агачыннан өзелсә,

Ул — алма, мөддәте тулганда пешкәч,
Кызаргач һәм матур булгач, җитешкәч.

Габдулла Тукай

Башкарды: Казан шәһәре 54нче урта мәктәбенең туган тел укытучысы
Шәвәлиева Лилия Фердинанд кызы

Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры

Казанда урнашкан,
татарларның беренче һөнәри театр коллективы Сәйяр нигезендә оештырылган, татар театрлары арасында әйдәп баручы театр

1986нчы елның 5 ноябрендә театрның яңа бинасы тантаналы рәвештә ачыла

Фәрит Бикчәнтәев режиссер

Якупов Илфир Илшатович директор

Казан, Татарстан ур., 1

К.Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры

1933нче елның

6 нояберендә ачыла

1988нче елда театрга К.Тинчурин исеме бирелә

2009 елда, шул исәптән, фасадны һәм ак-яшел тон интерьерларын яңартуны да кертеп, бинаны комплекслы төзекләндерү һәм реконструкцияләү буенча күп еллык проект тормышка ашырылды.

Башта бина Торак йорт (1850 ел, архитектор Скаржинский) булган. «Яңа театр " буларак йортның тарихы 1912 елда башлана (реконструкция проекты авторы — архитектор Ф.Р. Амлонг)

МӨСӘГЫЙТОВ ФӘНИС НАИЛ УЛЫ

шәһәрнең үзәк өлешендә элеккеге Арча кыры янында, Горький ур., 13 адресы буенча урнашкан.

М.Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театры

Дәүләт тарафыннан саклана торган архитектура һәйкәле

Театр 1939 нчы елда ачыла, шул вакыттан бирле республикада музыкаль мәдәният үзәге булып тора

1956 нчы елда аңа татар халкының атаклы шагыйре М.Җәлил исеме бирелә. Бинаның архитекторлары Н.Скворцов һәм И.Гайнетдинов.



Казан, Ирек мәйданы ур., 2

Татар дәүләт «Әкият» курчак театры

1934 елда оештырылган театрның дистә еллар үз бинасы булмый. Башта Профсоюзлар урамында почмак арендалый. Аннан яшь тамашачы театрының бер өлешенә урнашып тора. 1959 елда гына Изге рух иңү чиркәвенең (рус. Духосошественская церковь) (1731-1735 елларда Постау бистәсе сәүдәгәре Иван Михляев акчасына тол хатыны Евдокия Дрябкина-Михляева төзеткән) икенче катын бирәләр. 1970 елда беренче каттагы фатирларны күчереп бетергәч, театр Луковский урамындагы элекке чиркәү бинасына тулы хуҗа була

Театрның Питырбур урамындагы яңа бинасын төзүгә 4 ел вакыт китә (2008 – 2012)

Казан, Петербург урамы, 57

Г. Кариев исемендәге Казан Татар дәүләт яшь тамашачы театры

1996 елда театрга Казанның Киров районында урнашкан Җитен комбинатының Мәдәния йорты (элекке Алафузов театры, Эшчеләр театры) бинасын бирәләр. 2012 елда бина «авария хәлендә» дип табыла

2018 елның апреленнән театр реконструкция уздырылган элекке Җиңү (рус. Победа) кинотеатры бинасында (алдарак Офицерлар йорты булган) урнаша. Яңартылган бинаны тантаналы ачуда ТР президенты Р. Н. Миңнеханов катнаша

Бина төзелгән 1957 (кинотеатр)

Нигезләнү елы

- 1918 Алафузов театры балалар труппасы
- 1932 Татар яшь тамашачы театры
- 1949 Татар яшь тамашачы театры
- 1987 Татар театр-студиясе
- 1991 Кариев театры

- Казан, Петербург ур., 55б

Казан дәүләт яшь тамашачылар театры

2001 нче елда театр бинасына реконструкция эшләре башкарыла

Бу бина XIXгасырның икенче яртысында төзелә.

1917 нче елга кадәр монда сәүдәгәләр оешмасы була. Революциядән соң бу бинада татар мәдәнияте йорты ачыла.

Беренче спектакль 1932нче елда күрсәтелә.

Казан, Островский ур., 10

В. М. Качалов исемендәге рус драма театры

Хәзерге вакытта театр урнашкан бина 1833 елда сәүдәгәр Синяков өчен төзелгән, аннары берничә тапкыр үзгәртеп корылган. 1914 елда ул фильмнарны күрсәтү һәм драмаларны һәм оперетларны кую өчен заллы ахыргы төс ала.

Үзенең эшен 1791 елдан башлап алып бара.

Хәзерге вакытта театр урнашкан бина 1914 елда төзелгән

1948 елда театрга Василий Качалов исеме бирелә

Казан шәһәре, Бауман ур., 48

Әлмәт татар дәүләт драма театры

Нигезләнү елы 1944

1944 елның 3 февралендә Әлмәт район башкарма комитеты Әлмәттә театр булдыру турында карар чыгара

Баштагы чорда мәдәният йортында урнаша, 1973 тә театрга яңа спектакльләр әзерләү өчен аерым эш бинасы бирелә, 1985 тә мәдәният йорты бинасы театр өчен үзгәртеп җиһазландырыла.

1944 елда колхоз-совхоз театры буларак ачыла, 1951 дән драма театры, 1985 кә кадәр күчмә театр

Әлмәт шәһәре, Ленин ур., 37

Г. Тукай исемендәге Әтнә дәүләт драма театры

Татарстанның Әтнә районы Олы Әтнә авылында 1919 елдан эшләп килүче, дәүләт карамагындагы һөнәри театр, мохтариятлы мәдәният оешмасы. 2011 елдан дәүләт статусына ия

Нигезләнү елы 1919
Бина төзелгән 2005

Театр режиссеры — Рамил Фазлыев, ТР атказанган сәнгать эшлеклесе.

Театр директоры — Ленур Зәйнуллин.

Әтнә районы, Олы Әтнә авылы, Совет ур., 2А

А. В. Баталов исемендәге Бөгелмә дәүләт рус драма театры

Нигезләнү елы 1935

Бина төзелгән 1897

2008 елда Татарстан президенты М.Ш. Шәймиев инициативасы белән Бөгелмә дәүләт урыс драма театрына А.В. Баталов исеме бирелә

1900 елда Самар губернасының өяз шәһәре булган (1920 елга кадәр) Бөгелмәдә Халык йортында (хәзер театр урнашкан бина) театр-чәйханә эшләгән

Бөгелмә районы, Бөгелмә шәһәре, Ленин ур., 28

Буа дәүләт драма театры

2007 елның 30 мартында ТР Президенты М.Ш. Шәймиев Указы белән беренче профессиональ Буа дәүләт драма театры оештырыла.

1917 елның 4 маенда Буа шәһәренең татар шәкертләре һәм укытучылары «Казанга сәяхәт» спектаклен тәкъдим иттеләр.

1924 елда Казаннан республиканың беренче атказанган артисты Бари Тарханов килә, театр бинасын төзү белән шөгыльләнә. Бу театрга Кариев исеме бирелә. Биредә 12 кешедән торган Тарханов труппасы эшли. 1926 елда Б. Тарханов китә, аның эшен Зөләйха Богданова дәвам итә һәм мондый төр театр 1949 елга кадәр эшли.

Бөек Ватан сугышы елларында Күчмә театр урнашкан. Ул 1950 елга кадәр соңрак халык театрлары буларак иҗат итә, беренче үзешчән театрларның традицияләре дәвам итә, үсә. Һөнәри Буа дәүләт драма театры барлыкка килә.

Буа җирендә театрның яңа тормышы 2002 елның 16 февралендә башлана, укытучы Раил Садриев җитәкчелегендәге Энтузиастлар труппасы Мәдәният йортына Туфан Миңнуллин пьесасы буенча куелган "Гөргери кияүләре" спектакленең беренче репетициясенә җыелгач, шул вакыттан бирле яшь коллективның 60 тан артык постановкасы бар.

Буа шәһәре, К. Маркс ур., 68

С. Өметбаев исемендәге Минзәлә дәүләт татар драма театры

Нигезләнү елы 1935

Бина төзелгән 1894

Минзәлә театры 1894 елда төзелгән бинада урнашкан. Ул «Халык аудиториясе бинасы» буларак, Уфа земствосы акчасына төзелгән. 1999 елда капиталь төзекләндерү тәмамлана. Янкорма өстәлә.

1935 елда Беренче районара колхоз-совхоз театры нигезендә Минзәлә һөнәри колхоз-совхоз театры төзелә

Минзәлә районы, Минзәлә шәһәре, М. Җәлил ур., 19А

Яр Чаллы дәүләт татар драма театры

Нигезләнү елы 1990

Башта театр «Яшь тамашачылар театры» дип атала. Бу турыда Татарстан АССР Министлар Советының 1990 елның декабрендә чыккан №467 карары һәм ТАССР Мәдәният министрлыгының 1991 елның 10 гыйнварында дөнья күргән №8 фәрманы сөйли.

1995 елның 24 февралендә Чаллы шәһәре хакименең №395/4 карары нигезендә театрның исеме «Яр Чаллы татар драма театры» дип үзгәртелә һәм ул коммуналь учреждение буларак теркәлә. 1999 елның 1 сентябрендә Татарстан Республикасының Министрлар Кабинетының №573 карары нигезендә театр ТР Мәдәният министрлыгы карамагына тапшырыла.

Яр Чаллы шәһәре, Х. Туфан пр., 15 (4/16-А)

Т. Миңнуллин исемендәге Түбән Кама дәүләт татар драма театры

1989 елда «Нефтехим» берләшмәсенең яшьләр татар студиясе буларак оештырыла.
1994 елда театр шәһәр мәдәният идарәсе карамагына күчә, Татар яшьләре театры итеп үзгәртелә.

1997 елда Түбән Кама татар драма театры статусы ала.

2007 елда театрга дәүләт театры статусы бирелә.

2012 елда театрга Туфан Миңнуллин исеме бирелә

2019 елның 29 декабрендә яңартылган бинаны ачу һәм Түбән Кама татар дәүләт драма театрының 30 еллыгы тантанасында ТР мәдәният министры Ирадә Әюпова, Түбән Кама мэры Айдар Метшин катнаша

Түбән Кама районы, Түбән Кама шәһәре, Кайманов ур., 9